ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　КАРАР

2019 елның «11» октябре　　　　№ 1450

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «2018 елда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләреннән килгән сөт эшкәртүгә субсидияләр бирү турындагы Нигезләмәне раслау турында» 2019 елның 26 апрелендәге 574 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78нче статьясы нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга субсидияләр бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында» 2016 елның 6 сентябрендәге 887нче номерлы карары, «2013-2020 елларга авыл хуҗалыгы продукциясен тотрыклы җитештерү турында» муниципаль максатчан программа нигезендә, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «2018 елда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләреннән килгән сөт эшкәртүгә субсидияләр бирү турындагы Нигезләмәне раслау турында» 2019 елның 26 апрелендәге 574 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.2 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“субсидия алучы юридик зат - ликвидация, банкротлык процессында булырга тиеш түгел, ә субсидия алучы-шәхси эшмәкәр буларак эшчәнлеген туктатмаган булырга тиеш;»;

2018 елда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләреннән алынган сөт эшкәртүгә субсидияләр бирү турындагы нигезләмәгә 2нче кушымта таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| N п/п | Субсидия алучы предприятиенең исеме | Фактик урнашкан урыны | ИНН | Эшкәртү өчен китерелгән барлык сөт | Субсидия ставкасы | Субсидия барлыгы, сумнарда |
|---|---|---|---|---|---|---|

3. Әлеге карарны рәсми публикатор - «Лениногорские вести» газетында бастырып чыгарырга һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Җитәкче Н.Р. Залаков

И.Р. Хәйбрахманов, 5-44-72